# Яхшылык һәм начарлык

“ Я х ш ы л ы к
э ш л ә р г ә
а ш ы г ы й к !”

# Киңәш

- Әхлаклы бул, әдәпле бул:
- Яратыр олы, кече.
- Дөньяда иң әйбәт кеше
- Яхшылык кылган кеше.

# “Тәмамланмаган җөмлә”

- 1. Яхшылык – ул … .
- 2. Начарлык - ул … .
- 3. Яхшы кеше – ул … .

# “ Вөждан газабы”

Боргалана – сыргалана
Йоклап китәлми Ләлә.
Әнисе дә сизеп алды:
“Аврыйсыңмы әллә?”
“Юк”,- дигән булды да кызый,
Бер мәлгә туктап калды.
Күзен яшерде юрганга,
Авыр итеп тын алды.
“ Әйткәч әйтим, әни, - диде –
Бүген мин трамвайда
Урынымны бирмәдем, ди,
Басып торган бабайга.
Ышан әни, мондый хәлләр
Башкача кабатланмас
Хатаңны аңлагач, кызым,
Вөжданың газапламас.



# Төркемнәрдә фикер алышу

- 1. Яхшы эшләр эшләмичә генә яхшы кеше булып буламы?
- 2. Кешене яхшы булырга мәҗбүр итеп буламы?
- 3. “Кешеләргә карата яхшы булуның башы – бүтәннәрне кичерә белүдә”, дигән фикер белән килешәсезме?

# Балалар кылган яхшылыклар














ШКОЛА







# “ Афәрин!”





Кемнәрнең яхшылык эшләгәне бар, басыгыз!

Кемнәр транспортта өлкәннәргә урын бирә, басыгыз!

Кемнәр үзеннән кечкенәләргә ярдәм итә, басыгыз!

Кемнәр хайваннарны рәнҗетми, басыгыз!

Кемнәр әти – әнисенә ярдәм итә, басыгыз!

# Яхшы гамәлләр турында халык


1. Кешегә яхшылык итсәң, үзеңә файда булыр.
   Яхшылык иткән кешенең файдасын бел.

2. Яхшылык итсәң, яхшылык күрерсең.
   Яхшылык ташны да эретә.

3. Яхшылык итсәң, яшер, яхшылык күрсәң – белдер.
   Яхшылык ит тә, диңгезгә ташла, балык белер, .. балык белмәсә, халык белер.

# Нәтиҗә агачы

- 1. Әңгәмә файдалы булды.
- 2. Минем сорауларым калды.
- 3. Әңгәмә нәтиҗәле булмады.



# Киләчәккә бурычлар

- Кешеләргә игътибарлы, шәфкатьле, миһербанлы булырга.
- Табигатькә, хайваннарга карата мәрхәмәтле булырга.
- Һәр көн игелекле гамәлләр кылырга, изге эшләр башкарырга.
- Яхшылык барысын да җиңәчәк.
- Кылган эшләрең белән мактанып йөрмәскә.